*/ Чал тарихта эзле без!*

**1994.10.** – авылда мәчет ачыла, дини белем бирү торгызыла.
**1995.09.** – авылда урта мәктәп ачыла.
**2003-2004 еллар** – Майна юлына асфальт җәелә башлый**, 2010 ел** – асфальт авыл эченә кадәр җиткерелә.
**2004.11.** – авыл өйләренә телефон кертелә.
**2006 ел** – кумәк хуҗалык ВАМИН агрофирмасына кушыла, зират тимер коймa белән тотыла
**2007.06.** – авыл интернет челтәренә тоташтырыла.
**2011.08.** – Түбән Майна мәктәбе Иске Әдәм авыл җирлегенең база мәктәбе статусы ала.
**25. 08.2014** – яңа мәктәп һәм балалар бакчасы бинасы ачыла.
**2015-2023 еллар** – авыл урамнарына таш түшәлә.

*/ Укучылар иҗаты /*



## *Авылыбыз белән горурланам*

Мин Казан шәһәрендә яшим. Җәйге каникулда авылга әби белән бабай янына кайтып йөрим. Быелгы җәйге каникул минем өчен бигрәк тә истә калды. Чөнки мин авылыбыз мәчете каршында оештырылган лагерьга йөрдем. Ул бик үзенчәлекле булды, миңа бик ошады. Бу җәйләүдә бик күп нәрсәләргә өйрәндем: яңа сүрәләр, тәһарәт алырга, намаз укырга, гарәп алфавитын, авылыбызның тарихын. Шулай ук үземә яңа иптәшләр, дуслар таптым. Авылыбызның табигате дә бик матур һәм бай икән.

Мин авылыбыз белән, авылда яшәүче әби-бабай белән, бөтен кешеләр белән горурланам. Киләчәктә дә шундый лагерь оештырылса, мин бик теләп катнашыр идем.

*Данияр Хаметов*

## *Җәйләүдә*



Җәйләүнең беренче көнендә без бер-беребез белән таныштык, безгә җәйләү ничек узачагын, нәрсәләр өйрәнәчәгебезне аңлаттылар. Авыл җирләрен карап велосипедларда күп йөрдек. Безгә татар халкының тарихын, гарәп алфавитын, сүрәләр, догалар өйрәттеләр. Бер көнне безгә кызыклы тәҗрибәләр күрсәттеләр. Без әле Болгар белән Биләргә дә барып кайттык. Анда бик кызык булды, бик матур җирләрне күрдек. Ә соңгы көнне без пикник оештырдык, вакыт бик рәхәт узды. Иң истә калган көн Болгарда булды. Без анда тарихи урыннарга, музейларга кердек. Анда иң зур Коръән китабын күрдек.

Бу җәйләүне оештыручыларга, ярдәмчеләргә, әти-әниемә, әби-бабайга бик зур рәхмәт. Әниемнең туган җирен өйрәндем, үземә дуслар таптым, күбрәк татарча сөйләшә ала башладым.

*Мәрьям Катнова*




## *Дини кроссворд*

1 – мөселманнар дине.
2 – мөселманның көнгә 5 тапкыр үтәргә тиешле вазифасы.
3 – Рамазан аенда башкарылырга тиешле гыйбадәт.
4 – мөселманнар көтеп алган изге ай.
5 – соңгы пәйгамбәр
6 – дини бәйрәм.
7 – мөселманнарның изге китабы.

*Таһир Туктамышев*

**Газетаны гамәлгә куючы** **– Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары:** **Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Тәхвәтуллин**

# *Мәктәп хәбәрчесе*

**№6**
**(№57)**
**июль**
**2024 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

*/Мөгаллим киңәше/*

## *Шәһәрдән кайткан балалар өчен җәйләү*



Җир йөзендә яшәүче һәркемнең үзеннән алда яшәгән нәсел буыннары белән бәйләнеше булырга тиеш. Шушы бәйләнеш барлык туганнарны бергә җыя торган төп нигез аркылы тәэмин ителә. Буыннар бәйләнеше өлкәннәрнең тормыш тәҗрибәсен, ана телен, ата-бабаларыбыздан калган динне, гореф-гадәтләрне, гомумән алганда халыкның мәдәни мирасын яшьләргә тапшырырга мөмкинлек бирә. Барыбызга да билгеле булганча, дөньяда татар шәһәре булмаганлыктан, мәдәни мирасын саклау һәм киләсе буыннарга тапшыру вазифасын авыллар башкарып килде. Соңгы бернichә дистә елда авыллар тирән кризис кичергәнлектән, милләтнең күпчелек өлеше шәһәрләрдә тупланды. Ә шәһәрләр исә халыкның милли үзенчәлекләрен саклауны тәэмин итә алмый. Нәтиҗәдә халык милләт булудан туктап, кулланучылар массасына әверелә бара.

Шәһәрдә яшәүчеләрнең җәй көннәрендә балаларын авылга кайтару күренеше күптәннән үк барлыкка килде. Чикләнгән вакыт дәвамында булса да, әби-бабай янында яшәү балаларга күпмедер дәрәҗәдә милли сыйфатларны сеңдерергә мөмкинлек бирә. Ләкин бу эш махсус оештырылып, максатчан рәвештә башкарылса, нәтиҗә күпкә отышлырак булыр иде. Шуны күздә тотып, инде күптәннән ничек итеп авылга ялга кайткан шәһәр балалары өчен милли эчтәлекле чара оештыру турында уйланып йөргән идем. Башта бу эшне башлап җибәрергә тиешле таләпләргә җавап бирерлек урын юклыгы тоткарлык тудырса, аннан соң вакыт җитмәү һәм башка уңайсызлыклар сәбәп булды. Инде менә быел Рамазан аенда, үзебезнең мәктәптән чыккан укучыларыбыз уздырган ифтар мәҗлесендә, шушы мәсьәләне күтәреп чыктык. Сөйләшүдә катнашкан әти-әниләр әгәр авылда җәен шундый чара үткәрелсә, балаларын бик теләп кайтарабыз дигән фикерләрен белдерделәр.



**Түбән Майна авылында шәһәр балалары өчен җәйләү 1 – 14 нче июль көннәрендә уздырылды. Аның төп максаты – нәсел тамырлары Түбән Майна авылыннан булган, хәзерге вакытта төрле шәһәрләрдә яшәүче балаларга халкыбызның мәдәни мирасын җиткерү аркылы аларның милли үзаңнарын үстерү дип билгеләнде.** Шушы максатка ирешү өчен балаларга Ислам дине нигезләрен, милләт һәм авыл тарихын өйрәтү, халык мәдәнияте һәм туган як табигате белән таныштыру, нәсел шәҗәрәләрен барлау, ана телебездә аралашу күнекмәләрен ныгыту кебек мәсьәләләрне хәл итү каралды. Җәйләүдә барлыгы 14 бала катнашты. Шуларның унбере авылгы кунакка кайткан балалар, өчесе авылда яшәүчеләрдән иде. Чыгышлары буенча караганда, катнашучыларның дүртесе Казаннан, өчесе Чаллыдан, икесе Алексеевск бистәсеннән, берәр бала Чистайдан һәм Түбән Камадан иде. Кечерәк яшьтәгеләр арасында катнашырга теләүчеләр булса да, чараның программасыннан чыгып, 10 яшьтән өлкәнрәк булган мәктәп укучыларын гына алдык.

Җәйләү программасы буенча уздырылырга тиешле чаралар фәнни һәм гамәли өлешләрдән торды. Иртәдән алып төшкә кадәрге вакытны балалар дәресләрдә үткәрделәр. Дәресләр Ислам дине нигезләре, намаз уку тәртибе, гарәп графикасы, татар халкы тарихы, туган төбәк тарихы буенча уздырылды. Дин һәм гарәп язуы дәресләрен кызлар һәм малайлар аерым төркемнәрдә укыдылар. Балалар кирәкле китаплар белән тәэмин итеде. Дәрес темалары буенча эш дәфтәрләре алып барылды. Укыту татар һәм рус телләрендә алып барылса да, җавап алганда татарча сөйләүгә өстенлек бирелде.



Тәнәфес вакытында балалар гадәттә волейбол уйнады. Дәресләр тәмамлангач, төшке ашка керделәр. Айгөл апалары аларны бик тәмле итеп әзерләгән ризыклар белән сыйлады. Җыештыручы Галия апалары да ашханәне һәм уку бүлмәләрен чисталыкта һәм тәртиптә тотты. Төшке аштан соң балалар тәһарәтләрен алып, мәчеткә өйлә намазына бардылар.

Өйләдән соң җәйләүнең гамәли чаралары үтәлде. Аларның күпчелеге авылның истәлекле урыннары һәм аның тирәсендәге елга, күл, болыннарга сәяхәтләрдән гыйбарәт булды. Якын араларга җәяүләп, ераграк урыннарга велосипедлар белән бардык. Бер көнне җигүле атта йөрү мөмкинлеге булды. Табигатькә чыкканда балаларга барасы урынның спутниктан төшерелгән маршрут планнары таратылды. Шул планда алар төрле урыннарның атамаларын язып билгеләп бардылар. Беренче атнаның җомга намазыннан соң зиратка барып, вафат булган туганнарының каберләрен барлап, әрвахлар рухына дога кылып кайттык. Гамәли чаралардан дүрт мастер-класс та уздырылды. Укытучы Рифкать абыйлары химия һәм биология фәннәреннән кызыклы тәҗрибәләр күрсәтте. Шәҗәрә дәресендә балалар үзләренең нәсел буыннарын һәм тамырларын барлау серләренә өйрәнделәр. Милли сәнгать буенча мастер-классны авыл мәдәният йорты мөдире Алсу апалары үткәрде. Милли ризыклар турында балаларга әти-әниләр хушлашу чарасы барышында сөйләделәр.



Җәйләвебезнең ике көне татар халкының тарихи җәүһәрләре булган борынгы Биләр һәм Болгар шәһәрләренә сәяхәттә үтте. Андагы музейлар һәм истәлекле урыннарда йөреп, укучылар бай һәм данлыклы тарихыбыз белән якыннан таныштылар. Шәһри Болгарда безнең төркемгә мәктәбебезнең күптәнге дусты, күренекле галим Җәмил абый Мөхәммәтшин экскурсия үткәрде. Биләргә баргач археологларның борынгы тимерчелек бистәсендәге казу эшләре белән таныштык. Хуҗалар тавы түбәсенә менеп туган ягыбызның матурлыгы белән хозурландык.

Программада каралган булса да, җәйләүнең кайбер чараларын үткәрү мөмкин булмады. Болар, беренче чиратта, Чирмешәннең аргы ягындагы истәлекле тарихи урыннар – Чәчәби тавы һәм Чишмәсе, Чуаш әрәмәсе, Югары кыр һәм андагы тирән тирән чокырлар, мәктәп посадкасы, Саржинат болыны, Иске авыл урыны һәм Иске авыл зиратына бара алмадык. Моның сәбәбе – Чирмешән аркылы чыгарга мөмкинлек бирә торган буаның буылмавында.

Җәйләүнең йомгаклау чарасы - балалар һәм әти-әниләр белән берлектә сахрага чыгу булды. 14 июль иртәсендә барыбыз да җыенып, туган ягыбызның иң гүзәл урыннарыннан булган урынга – Чиялек астындагы Чирмешән буендагы болынга юл алдык. Болынга барып җиткәч, чатырларны корып табын өчен урын әзерләдек. Әти-әниләр уха пешерү һәм компот кайнату өчен казан асу, корбан итләреннән шашлык кыздыру белән мәшгуль булдылар. Малайлар учак өчен утын әзерләде. Шуннан соң балалар төрле уеннар уйнадылар, уктан ату буенча ярыштылар. Елганың бу турысында кондызлар Чирмешәнне буып аргы ярга чыгарга кичү әзерләп куйганнар иде. Шул урыннан аргы якка чыгып, Чиялек һәм аның янындагы борынгы кала урыны белән танышу мөмкин булды. Төшке ашны ашагач, балаларның һәрберсе үзләре белгән Коръән сүрәләрен укып чыктылар. Шуннан соң бергәләшеп дога кылып, “Туган тел” җырын җырлап, сахрадагы ялыбызны төгәлләдек.

Болыннан кайткач, җәйләвебезгә нокта кую өчен, балалар мәчет манарасына менеп авыл белән хушлаштылар. Майнабыз да аларны **“Сез бит миннән очкан кошларның балалары, ташламагыз инде ата-бабаларыгызның мөкатдәс нигезләрен”** – дигән кебек моңсуланып озатып калгандай булды. Һәр кирәкле һәм игелекле гамәлнең дәвамлы булуы хәерле. Балаларның теләге һәм әти-әниләренең тәкъдимнәре дә шундый җәйләүләрнең алдагы елларда да уздыру турында иде. Шуларны истә тотып, Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, яшь буынны милләтебезгә һәм туган туфрагыбызга бәйли торган чараларны уздырып торырга ниятлибез. Амин.



***Рафик Насыйров,***
***Түбән Майна урта мәктәбе директоры***

*/ Чал тарихта эзле без! /*

## *Түбән Майна авылы тарихында булып узган истәлекле вакыйгалар*

**Б.э.к. 2000-1500 еллар** – авыл тирәсендәге җирләрдә «бура» культурасы кабиләләре яши.
**IV-V гасырлар** – безнең якларда һун кабиләләренең күчеп йөрүе.
**VII-VIII гасырлар** – авыл тирәсендә «Имән Кискә» культурасы кабиләләре яшәгән чор.
**IX-XIII гг.** – безнең төбәк Болгар дәүләтенең үзәк өлешендә кала. Ул дәвердә Майна җирләрендә алты авыл булган.
**XIII-XIV гасырлар** – Алтын Урда чоры. Ул дәвердә Майна җирләрендә дүрт авыл булган.

**1360 еллар** – Иске авыл нигезләнә. XIV- XV гасырларда авыл халкы тимер эретү һәм чуен кою белән кәсеп иткән.
**XVI гасырның беренче яртысы** – Иске авылының мәчете төзелә.
**1654 ел** – Биләргә стрелецлар килеп урнаша. Авыл җирләренең көнбатыш чикләре билгеләнә.
**1700 еллар башы** – Иске авылга чуашларның беренче төркеме килеп урнаша.
**1717 ел** – Иске Әдәм авылы белән ике арадагы җир чикләре билгеләнә.
**1725 ел** – шушы елдан алып Иске авылда су тегермәне билгеле.
**1730 еллар** – Иске авыл аркылы лашманчыларның йөри башлавы.
**1743 ел** – чукындыручылар тарафыннан Иске авылның мәчете җимерелә.
**1749-50 еллар** – Иске авылдагы чуашларның күпчелеге һәм берничә татар кешесен көчләп чукындыру.
**1750 еллар** – чукынмаган татарлар һәм чуашларның авылның хәзерге урынына күченеп урнашуы.
**1780 еллар** – Иске авылда калган чуашларның хәзерге Чуаш Майнасы урынына күченүләре.
**1786 ел**. – Түбән Майнада мәчет төзелә.
**1829 ел** – шушы елдан авылда мәктәп булганлыгы билгелеавылда мәдрәсә ачылу.
**1837 ел** – Биләр волосте оештырыла. (Түбән Майна һәм тирә-яктагы 7 авыл белән бергә).
**1878 ел ахыры** – авыл халкының хөкүмәт сәясәтенә каршы чуалышларда катнашуы.
**1905-1907 еллар** – авылда яңа мәчет һәм мәдрәсә биналары төзелә.
**1914-1918 еллар** – авылдан 70-ләп ир-атның Беренче Бөтендөнья сугышында катнашуы.
**1917 ел ахыры** – авылда совет хакимияте урнаша. Җирләр яңадан бүленә.
**1918 ел** – авыл мәдрәсәсе беренче баскычлы совет мәктәбе итеп үзгәртелә.
**1918. 02.** – авыл халкының гражданнар сугышына тартылуы. Авылга җәза отрядының килүе.
**1919. 03.** – авылдан 5 кешенең “кызыл террор” сәясәте барышында Мөслим авылы янында атылуы.
**1919.**05. – авылга аклар гаскәренең килүе.
**1920 ел** – Майна халкының большевиклар хөкүмәтенә каршы күтәрелгән сәнәкчеләр фетнәсендә катнашуы.
**1921 ел – 1922 ел кышы** – котычкыч ачлык һәм тиф чиреннән авылда 100ләп кеше вафат була.
**1923 ел** – авыл җирләрен яңадан бүлү.
**1929. 11**. – беренче күмәк хуҗалык оешу. («Йолдыз» колхозы)
**1930-1931 еллар** – кулак категориясенә кертелгән хуҗалыкларны авылдан сөрү.
**1932. 07.** – ут чыгып, авылның бер урамы тулысынча диярлек янып бетә.
**1937. 09-10.** – халык дошманы буларак гаепләнгән 4 кешене кулга алу (өчесе атып үтерелә).
**1938.12.** – авылның мәчете ябылала; **1939. 08.** – манарасы киселә.
**1941-1945 еллар** – авылның 160лап кешесе Бөек Ватан сугышында катнаша. Аларның 91-е кире әйләнеп кайтмый.
**1947-1951 еллар** – Чирмешән елгасын буып төзелгән гидроэлектростанциянең эшләве.
**1953-1957 еллар** – Түбән Майна һәм Чуваш Майнасы бер колхозга берләшә.
**1957 ел** – Түбән Майнада аерым авыл советы бетерелеп һәм Шәмә авылы белән берләштерелә.
**1958 ел** – МТСларны бетерү нәтиҗәсендә колхозга комбайн һәм тракторлар кайтарыла.
**1959 ел** – авылда медпункт эшли башлый
**1961 ел** – Түбән Майна, Такталы һәм Әдәмсуы авыллары уртак авыл советына һәм“Киров” колхозына берләшә.
**1963. 01.** – Биләр районы бетерелә, авыл Октябрь районына кушыла. **1964. 03.** – Алексеевск районында.
**1963-1965 еллар** – авылны Зәй ГРЭСыннан килүче электр челтәренә тоташтыру.
**1963-1965 еллар** – авылда яңа мәктәп бинасы төзелә;
**1965. 08.** –сигезъеллык мәктәп ачыла.
**1966 ел** – колхозчыларга хезмәт хакы акчалата түләнә башлый.
**1970 еллар** – авылда яңа терлекчелек фермалары, **1975-1976 еллар** – яңа клуб бинасы, **1977 ел** – яңа гараж төзелә.
**1977 ел ахыры** – Киров исемендәге колхоз Аксубай районына күчерелә.
**1978 ел** – авылда балалар бакчасы ачыла.
**1987. 12.** – Түбән Майна Киров исемендәге колхоздан аерылып «Уңыш» колхозы буларак теркәлә.
**1988 ел** – Түбән Майна белән Иске Әдәм авыллары арасында күтәртелгән юл салына.
**1989 ел** – авылда кибет һәм медпункт бинасы, яңа ындыр табагы төзелә.
**1992 ел** – колхозчыларга хезмәт хакын акчалата бирү туктатыла.
**1992-1993 еллар** – авылнга су кертү.
**1993-1994 еллар** – авылны газлаштыру.
**1990 еллар** – авылда газ кертелү сәбәпле яңа кирпеч йортлар төзелү.

**/ Мөгаллим киңәше /**

## Дин – телне, тел динне саклый



Аллаһы Тәгалә "Рум" сүрәсендә: "Җир-күкләрнең төзелеше, телләрегез һәм төсләрегезнең төрле булуы Аллаһының галәмәтләреннән. Әлбәттә, Аллаһының бу эшләрдә белем ияләре өчен дәлилләр бар",-диелә. Дөньяда күптөрле халык яши. Алар төрле телләрдә сөйләшә. Бу – Аллаһы Тәгаләнең хикмәте. Һәр халык үзенең милләтенә һәм теленә игътибар биреп, аны ныгытуда, үстерүдә бөтен көчен салырга тиеш. Шуның белән халык үзенең милләтен һәм телен саклаячак.

Якташыбыз Хәсән ага Туфан: "Телне саклау җәмгыятьнең әйдәп баручы кешеләреннән тора",- дигән. Рафик абый Насыйровны мин нәкъ менә әйдәп баручы, туган телебезне, туган авылыбызны үстерү өчен барысын да эшләүче милләтпәрвәр дияр идем. Шәхсән үземне дә, иң элек сыйныф җитәкчесе буларак, Ислам диненә китерүче дә, туган ягыбызның матурлыгын күрсәтүче, тарихын ишеттерүче дә ул. Тәнәфескә дә чыкмыйча, абый (һәрвакыт аңа шулай дип дәштек, хәзер дә шулай эндәшәбез) сөйләгән хәдисләр; безнең нәселебез белән, авыл белән бәйле тарихи вакыйгалар гомерлеккә хәтергә сеңеп калган. Үзенең машинасына утыртып, безне, дүрт баланы, кая гына алып бармады ул: Болгарга да, Биләргә дә, тирә-якта урнашкан мәчетләр белән дә таныштырды, Гаяз Исхакый кебек мәшһүр язучыларыбыз музейларын да күрсәтте.



Рус мәктәбендә белем алучы, татар телен камиль белмәүче балаларыбыз өчен мөселман җәйләве ачылачагын әйткәч, бик шатландык. Башка мөселман җәйләүләреннән аермалы буларак, монда дини белем белән берлектә туган як, авыл, татар халкының тарихлары да өйрәтелде; ата-баба нигезенең мөһимлеге ассызыкланды. Бу мәгълүмат тарихи, дини урыннарыбызга сәяхәт белән үрелеп барылды.

Балаларыбызга шул мохиттә булу мөмкинлеге биргән Аллаһы Тәгаләгә, җәйләүне оештыручы абыйга, Гөлүса апага – һәр катнашучыга олы рәхмәтебезне белдерәбез. Әлеге эшегез дәвамлы һәм нәтиҗәле булсын.

*Диләрә Шакирова,*
*Алексеевск бистәсенең Г.С.Боровиков ис. 3 нче урта мәктәбе директоры*

**/Укучылар иҗаты/**

## Күңелле җәй



Без, Гайфетдинов Госман оныклары – Хәсәнова Мәрьям һәм Гатиятуллин Алинур, Чаллы шәһәрендә яшибез. Ел саен Түбән Майна авылына, бабам белән әбием янына, җәйге ялга кайтабыз. Бу елны авыл мәктәбендә шәһәр балалары өчен лагерь оештырдылар. Лагерьда без авылның табигатен, истәлекле урыннарын карап йөрдек. Без уйнап йөргән, кәтү キ.

Лагерьда без һәр көнне мәчеткә намазга бардык. Гарәп хәрефләрен, намаз тәртипләрен өйрәндек, Коръән сүрәләре һәм догалар ятладык. Төш вакытында безне бик тәмле ризыклар белән сыйладылар. Шуның өчен пешерүче апаларга зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Безнең лагерь ике атна дәвам итте. Һәр атнаны ерак экскурсияләргә бардык. Биләр һәм Болгар шәһәрләренә барып, андагы музейларда йөрдек. Лагерьның соңгы көнендә болынга ял итәргә чыктык. Монда безнең әти-әниләр дә килделәр. Аннан кайтканда мәчет манарасына менеп авылны карадык. Безгә авылдагы лагерь бик ошады.

*Мәрьям Хәсәнова һәм Алинур Гатиятуллин*

## Анкета уздыру нәтиҗәләре

**/Мәктәп тормышы/**

Җәйләүнең ахырында балаларның биредә үткәргән көннәр турында фикерләрен белү һәм киләчәктәге эшчәнлегебезне планлаштыру максатыннан анкеталау уздырылды. **“Җәйләүдә синең өчен иң мөһиме ни булды?”** – дигән беренче сорауга күбесе яңа белемнәр алу, аннан соң сәфәрләр һәм яңа дуслар табу дип җавап бирделәр.

**“Нинди вакыйгалар һәм кичерешләр аеруча истә калды?”** соравына беренчелекне “Биләргә һәм Болгарга бару”, икенче урынны “велосипедта төрле җирләргә йөрү” җаваплары алды. Бер бала “велосипед ватылып төркемнән артта калу” – дип язган. Димәк, балалар өчен тарихи һәм истәлекле урыннарга йөрү бик мөһим. Шул ук вакытта, әти-әниләр балаларын яхшы сыйфатлы техника белән тәэмин итәргә тиеш булып чыга.

**“Синең үзеңдә үзгәрешләр булдымы?”** соравына бирелгән җаваплар төрлерәк. Сорашылганнарның күбесе өчен дини белемнәрен арттыру мөһим дип исәпли. Икенче дәрәҗәдә тарихны яхшырак аңлау тора. Берәр бала “җитдирәк була башладым”, “дингә мөнәсәбәтем үзгәрде”, “татарча күбрәк аралаша башладым” – дип җавап биргән. Шулай ук бер укучыда “берни дә үзгәрмәде” – дигән җавап та бар.

**“Нинди яңа белемнәр алдың?”** дигән сорауга гарәп хәрефләрен һәм татар халкы белән туган як тарихын өйрәнү дип тигез дәрәҗәдә җавап биргәннәр. Әлеге җаваплардан бу балалар яшәгән җирлектә әлеге белемнәргә өйрәтү дәрәҗәсенең түбән булганлыгы беленә.

**“Җәйләүдә нәрсәгә булса да өйрәндеңме?”** соравына иң еш “күп нәрсәгә” дип җавап бирелгән. Калганнары гарәп хәрефләрен һәм яңа сүрәләр өйрәнүгә басым ясаган. “Мәктәптә һәм җәйләүдә алган белемнәр арасында аерма бармы?” – дигән сорауга берничәсе җавап бирә алмаган. Калганнарының күпчелеге мәктәптә дингә, ә кайберләре татар һәм туган як тарихына өйрәтмиләр дип җавап биргәннәр.

Алдан ук көтелгән булса да, безнең өчен җиденче – **“Гаиләдә, мәктәптә, яшьтәшләр белән нинди телдә аралашасың”** дигән сорауга алынган җаваплар иң үкенечлесе булды. Гаиләгә килгәндә, соралучыларның 30% гына гаиләдә татарча аралашабыз дип җавап бирде. Калганнарда гаилә теле русча-татарча булып чыкты. Барча балаларның да мәктәпләрендә тулысынча рус телендә аралашу гына хөкем сөрә. Ә дуслары белән 40% русча-татарча, калганнары русча аралашканнарын белдерделәр. Тулаем алганда, сорашу балаларның рус телле мохитта яшәүләрен күрсәтте. Вакытларының күп өлешен мәктәптә һәм яшьтәшләре белән уздыруларын исәпләсәк, бу яшүсмерләр ана телен югалту куркынычы алдында торалар. Шунлыктан, әти-әниләрдән балалары белән туган телләрен саклау һәм үстерү юнәлешендә бик тырышып эшләү таләп ителә.

**“Динне кайчан һәм кем йогынтысында өйрәнә башладың?”** соравына күпчелеге кече яшьтән һәм әни (әти-әни) йогынтысында дип җавап биргән. Бер укучы мөселман балалар бакчасына йөргәнлеген әйткән. Мондый җавап балаларның дини гаиләләрдән булуын күрсәтә. Бу уңайдан әти-әниләргә динилек һәм миллилек кошның ике канаты кебек булуын искәртәсе килә.

**“Җәйләүдә үткәргән вакыт киләчәк тормышыңа йогынты ясармы? Әгәр ясаса, ничек?”** дигән сорауга барысы да диярлек дин тотуга кагылышлы гамәлләрне тиешенчә башкарачакмын дип җавап биргәннәр. Моңа өстәп, яртысына якыны алган белемнәрен башкаларга өйрәтә алачакмын дип белдергән. Минә бу җавап бик мөһим, чөнки шулай фикерләү әлеге балаларда гаиләләре һәм җәмгыять алдында җаваплылык хисе барлыгын күрсәтә.

**“Өч “Рәхмәтне” кемнәргә һәм ни өчен әйтер идең?”** соравына Рафик абый белән Гөлүсә апага җәйләүне оештырган өчен, Айгөл апага тәмле пешергән өчен дип җавап бирелгән. Болардан тыш яңа белемнәр, сәяхәтләр, ярдәм иткәннәре һәм бик тыгыз программа өчен дигән җаваплар да бар.

Соңгы сорау нидән канәгать булулары һәм нәрсәдән ризасыз калулары турында иде. Канәгатьлек сәбәпләре шактый күп булса, җитешсезлек буенча барысы да бер төрле итеп, “лагерь кыска булды, тиз бетте” дип җавап биргәннәр.

Анкеталау балалар өчен белем бирү лагерьларының җәйге каникул көннәрендә дә актуаль булганлыгын күрсәтте. Шулай ук, бьелгы программа белән көн тәртибенең дөрес төзелгәнлеген, һәм җәйге ялның ким дигәндә 3 атна дәвам итәлергә тиешлеген раслады.

*Рафик Насыйров, Түбән Майна урта мәктәбе директоры*



# *Түбән Майна мәчете каршында оештырылган балалар җәйләве программасы*

| Көн | Чаралар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| 1 июль | Танышу, җәйләү тәртипләрен аңлату | 08.30 – 09.00 |
| | Ислам (әхлак) дәресе (Иман, Ислам, Ихсан. Диннең асылы) | 09.00 – 09.45 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку, ( ا رز م хәрефләре, иман кәлимәсе) | 09.50 – 10.35 |
| | Тарих дәресе (Татар халкының килеп чыгышы) | 10.40 – 11.25 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Шәһитләр мәчете”, “Каенлык елгасы”, “Хаҗи бабай күле”, “Әрәмә”, Чирмешән буе). | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 2 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Аллаһы Тәгаләгә иман. Тәһарәт) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку( ت ن ي хәрефләре, “Фәтихә” сүрәсе) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Туган ягыбыз борынгы чорда) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Шалканат” болыны, “Сәет күле”, “Чуаш басмасы”, Кәлим күлендә көймәдә йөзү). | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 3 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Фәрештәләргә, изге китапларга, пәйгамбәрләргә иман. Гыйбадәтләр) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( ب ك ل хәрефләре, “Ихлас” сүрәсе) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Туган ягыбыз X – XIIIгасырларда) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Карамалы табыр”, “Сукыр Чирмешән”, “Болгар” куаклыгы, “Каенлык”, “Арттагы күл”). | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 4 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Тәкъдиргә иман. Намаз) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( و ه ف хәрефләре, “Фәләк” сүрәсе) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Туган ягыбыз XIII – XVгасырларда) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Абдул посадкасы”, “Комлык”, “Имәнлек”, “Шәмә посадкасы”, “Туктаби”, “Шәмә юлы”). | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 5 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Кыямәт, Җәннәт, Җәһәннәм. Зәкәт, ураза, хаҗ). | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( ق ش س хәрефләре, “Нәс” сүрәсе) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Туган ягыбыз XVI – XVIIIгасырларда) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, җомга намазы | 11.30 – 12.40 |
| | Сәяхәт (Арттагы урамдагы иске каберлекне карау, авыл зиратына барып туганнарның, әби-бабаларның каберләрен барлау) | 12.40 – 14.40 |
| | | |
| 7 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Мөхәммәд (с.г.с.) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( ث ص ط хәрефләре, “Әт-тәхият” догасы) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Туган ягыбыз XIX – XXгасырларда) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Икесаз” елгалары, “Зур чирәм”, Буа, “Тирмән алды”, “Нәмәт бабай елгасы”) | 12.30 – 14.30 |
| 08.07. | Шәһри Болгарга сәяхәт (Колбай Мораса авылы музее, Әлки районы музее, Ак мәчеттә өйлә намазы Болгардагы Икмәк, Болгар мәдәнияте, Коръән музейлары) | 08.00 – 16.00 |
| | | |
| 9 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Гамәлләр, хәләл белән хәрам) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( ج ح خ хәрефләре, Салават әйтү) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Татар халкы мәдәнияте. Милли кул эшләре буенча мастер-класс) | 10.30 – 11.25 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Чуаш әрәмәсе”, “Чәчәби тавы”, “Чәчәби чишмәсе”, “Келәүле күл”, Мәктәп посадкасы, Тирән ерымнар) | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 10 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Ата-ана һәм туганнар алдында хаклар) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( غ ع د хәрефләре, “Раббәнә” догасы) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Татар халкының тормыш-көнкүреше. Милли ризыклар буенча мастер-класс) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Пәдер күле”, “Саржинат болыны”, “Иске авыл зираты”, Иске авыл урыны). | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 11 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Дин кардәшләр һәм җәмгыять алдында хаклар) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку ( ض ذ ظ хәрефләре, “Кәүсәр” сүрәсе) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Туган ягыбызда исламият тарихы) | 10.30 – 11.15 |
| | Төшке аш, өйлә намазы | 11.30 – 12.20 |
| | Сәяхәт (“Мәхсет елгасы”, “Лашман юлы”, “Олы күпер”, “Кәрәкә елгасы”, “Тукморза болыны”, “Мунчала күле”). | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 12 июль | Ислам (әхлак) дәресе (Кызлар белән малайлар арасында әдәп кагыйдәләре) | 08.30 – 09.15 |
| | Гарәби әлифба һәм Коръән уку (Мәдле хәрефләр, “Гасыр” сүрәсе) | 09.30 – 10.15 |
| | Тарих дәресе (Нәсел шәҗәрәләре, мастер-класс) | 10.30 – 11.25 |
| | Төшке аш, җомга намазы | 11.30 – 12.40 |
| | Мәчет манарасыннан авылны күзәтү | 12.30 – 14.30 |
| | | |
| 13.07. | Шәһри Биләргә һәм Хуҗалар тавына сәяхәт. Биләр мәчетендә өйлә намазы. Археологларның борынгы Биләрдәге казу эшләре белән танышу. | 08.30 – 13.00 |
| | | |
| 14.07. | Җәйләүне йомгаклау чарасы. Әти-әниләр белән бергә Тукморза болынында пикник. (“Әче куаклыгы”, “Чиялек”, “Югары кыр”, “Гәрлинкә” чокырлары). Алган белемнәр буенча имтихан | 08.30 – 14.00 |

